ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ

06. 04. 2017 г. Казань № 045-од

«2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы буенча 2017 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында

Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм бүтән архив документларын исәпкә алу, тулыландыру сыйфатын арттыруны, аларның сакланышын һәм алардан файдалануны алдынгы архив технологияләрен гамәлгә кертү һәм заманча җайланмаларны һәм техниканы үзләштерү, архив эше өлкәсендә югары нәтиҗәләргә тотрыклы рәвештә ирешүне, муниципаль берәмлекләрдә архив эшен оештыру өлешендә уңай тәҗрибә таралуны, муниципаль архивлар җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен үстерү исәбенә тәэмин итүче муниципаль архивларга ярдәм күрсәтүне стимуллаштыру максатларында, б о е р ы к б и р ә м:

1. «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.06.2016 № 395 карары белән расланган «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы буенча 2017 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурсны 2017 елның 1 июненнән алып 2 октябренә кадәр оештырырга һәм уздырырга.
2. 2017 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында нигезләмәне расларга.
3. Архив эшен үстерү һәм мәгълүмат хезмәт күрсәтүләрен оештыру бүлеге конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итәргә тиеш.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча
дәүләт комитетының
06.04.2017 № 045-од
боерыгы белән расланды

2017 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына
грант ярдәме алуга конкурс турында
НИГЕЗЛӘМӘ

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2017 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында әлеге нигезләмә «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.06.2016 № 395 карары белән расланган «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

Чарада катнашучылар – грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) – грантлар бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

Грантка дәгъва кылучы – Татарстан Республикасы муниципаль архивы.

Грант алучы – әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүче, конкурс сайлап алуын узган һәм әлеге Нигезләмәнең 1.6 пунктында күрсәтелгән номинацияләрдә 1 нче урыннан алып 5 нче урыннарны яулаган Татарстан Республикасы муниципаль архивы.

Грант – әлеге Нигезләмәнең 1.6 пунктында күрсәтелгән һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиесе һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә грант бирүче тарафыннан сатып алынган җайланмаларны һәм техниканы муниципаль берәмлекләрдә архив эшен үстерүгә юнәлгән чараларны гамәлгә ашыру өчен грант алучыларга билгеле бер вакытта тапшыру.

1.2. Конкурс гавами характерда була һәм, архив эше өлкәсендә муниципаль архивлар казанышларын исәпкә алып, ачык һәм коллегиаль принциплар нигезендә уздырыла.

1.3. Грант алучыларны конкурс сайлап алуы (алга таба – конкурс сайлап алуы) – Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм бүтән архив документларын исәпкә алу, тулыландыру сыйфатын арттыруны, аларның сакланышын һәм алардан файдалануны алдынгы архив технологияләрен гамәлгә кертү һәм заманча җайланмаларны һәм техниканы үзләштерү, архив эше өлкәсендә

югары нәтиҗәләргә тотрыклы рәвештә ирешүне, муниципаль берәмлекләрдә архив эшен оештыру өлешендә уңай тәҗрибә таралуны, муниципаль архивлар җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен үстерү исәбенә тәэмин итүче муниципаль архивларны стимуллаштыру.

1.4. Конкурс сайлап алуы бурычы – архив эше өлкәсендә, алдынгы архив технологияләрен гамәлгә кертүдә югары нәтиҗәләргә тотрыклы рәвештә ирешүне тәэмин итүче муниципаль архивларны ачыклау һәм бүләкләү.

1.5. Конкурс ике этапта уздырыла:

беренчесе, 2017 елның 1 июненнән алып 5 июненә кадәр – әлеге Нигезләмәнең 2.2 һәм 2.3 пунктлары нигезендә тапшырылган документация буенча Татарстан Республикасы муниципаль архивлары рейтингын формалаштыру;

икенчесе, 2017 елның 6 июненнән алып 2 октябренә кадәр – Татарстан Республикасы муниципаль архивлары тарафыннан алдынгы технологияләрне гамәлгә кертү исәбенә муниципаль берәмлекләрдә архив эшен үстерүгә юнәлгән проектларны һәм аларга кушымталарны әлеге Нигезләмәнең 2.13 һәм 2.14 пунктлары нигезендә тапшыру.

1.6. Конкурс Татарстан Республикасы муниципаль архивлары тарафыннан тапшырылган проектлар арасында өч номинация буенча уздырыла:

Номинация атамасы	Проектларны гамәлгә ашыру юнәлешләре	1 проектка җайланмалар саны
Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан Республикасы тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулыландыру проектларына ярдәм күрсәтү: 5 грант	Татарстан Республикасы Архив фондын тарихи, фәнни, социаль һәм мәдәни әһәмияттәге һәм Татарстан Республикасы тарихын телдән булдырганда барлыкка китерелгән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрендәге аудиовизуаль документлар белән тулыландыру	Комплект из Видеокамерадан, штативтан һәм и видеокамера чехолыннан, фотоаппараттан торган комплект, 360000 сумга.
Татарстан Республикасы Архив фонды документлары һәм бүтән архив документлары сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм күрсәтү: 5 грант	заманча архив технологияләрен кулланып, архив документларының сакланышын тәэмин итү	Архив документларын цифрлау өчен комплекс, 480000 сумга
Татарстан Республикасы Архив	Заманча архив технологияләрен кулланып, архив	Видеопроектордан, ноутбуктан, экраннан

фонды документларып һәм бүтән архив документларын популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм күрсәтү: 5 грант	документларын популярлаштыру, алардан файдалану һәм тикшеренүчеләрнең аларны карау мөмкинлеген тәэмин итү (Россия Федерациясе законнары нигезендә алу мөмкинлеге чикләнгән документлардан гайре)	һәм лазер күрсәткечтән торган комплект, 160000 сумга.

1.7. Конкурска тапшырылган проектларга эксперт бәя бирү һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен Экспертлар советы төзелә.

1.8. Конкурсны уздыру тәртибе, сроклары, шартлары һәм конкурста катнашу өчен сайлап алу критерийлары турында мәгълүмат Дәүләт комитетының тиешле боерыгы үз көченә кергән 5 (биш) эш көне эчендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла (www. http://arhiv.tatarstan.ru/, Грантлар бүлегендә).

II. Конкурста катнашуга хокук һәм документлар кабул итү тәртибе

2.1. Конкурсның беренче этабында Татарстан Республикасының барлык муниципаль архивлары да катнашырга хокуклы.

2.2. Конкурсның беренче этабында катнашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль архивы җитәкчесе имзалаган һәм муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе таныклаган заявка (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта) әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктындагы 1 нче абзацында күрсәтелгән срокларда Дәүләт комитетына тапшырыла.

2.3. Заявкага билгеләнгән тәртиптә таныкланган түбәндәге документлар кушып бирелә:

муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе имзалаган йөртү хаты;

Татарстан Республикасы муниципаль архивының расланган еллык хисаплары һәм 2014, 2015, 2016 елларга аларга карата аңлатма язулары күчермәләре;

2.4. Грант алуга дәгъва кылучыларны конкурска сайлап алуның беренче этабы критерие – Татарстан Республикасы муниципаль архивларының 3 еллык эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингы (алга таба – рейтинг).

2.5. Рейтинг балларны кушу юлы белән формалаштырыла. Баллар 2014-2016 елларда муниципаль архивның 1 штат берәмлегенә туры килүче эшләр күләме буенча Татарстан Республикасы муниципаль архивларының эшчәнлегенең Татарстан Республикасы муниципаль архивларының еллык хисапларындагы түбәндәге күрсәткечләре буенча биләгән позиция нигезендә (кими бару буенча) исәпләнелә:

	Эшләр төре	2014-2016 елларда башкарылган	2014-2016 елларда штат	2014-2016 елларда 1 штат берәмлегенә	Исемлектә биләгән позиция

		эшләр күләме	берәмлек-ләре саны	исәпләгәндә башкарылган эшләр күләме	номеры нигезендә баллар (кими бару буенча)
1.	архив документлары сакланышын тәэмин итү:				
1.1.	картонлаштыру				
1.2.	эшләрне тегеп кую				
2.	архив документларын исәпкә алу:				
2.1.	исәпкә алу документларын тикшереп чыгу				
2.2.	булуын тикшерү				
2.3.	документларның тасвирламасы (идарәчел, шәхси состав буенча, фотодокументлар, шәхси чыгышлы)				
2.4.	фондларны камилләштерү һәм описьларны эшкәртү				
2.5.	расланган тәртип һәм документларны исәпкә алу схемалары булу				
3.	архив документлары белән тулыландыру:				
3.1.	идарәчел документацияне кабул итеп алу				
3.2.	шәхси состав буенча документларны кабул итеп алу				
3.3.	фотодокументларны кабул итеп алу				
3.4.	шәхси чыгылышлы документларны кабул итеп алу				
4.	архив документларын файдалану:				
4.1.	социаль-хокукый				

	гарызнамәләрне үтәү				
4.2.	тематик гарызнамәләрне үтәү				
4.3.	мәкаләләр бастырып чыгару				
4.4.	радио-, телетапшыруларда катнашу				
4.5.	экскурсияләр оештыру				
	лекцияләр, әңгәмәләр, мәктәп дәресләре уздыру				
4.6.	күргәзмәләр оештыру				
4.7.	тикшеренүчеләргә документлар бирү				
5.	тулыландыру чыганаклары булган оешмалар белән хезмәттәшлек:				
5.1.	практик һәм методик ярдәм күрсәтү				
5.2.	тулыландыру чыганаклары булган оешмаларның даими рәвештә сакланучы эшләре описьларын раслау				
5.3.	килештерү:				
5.3.1.	тулыландыру чыганаклары булган оешмаларның шәхси состав буенча описьларын				
5.3.2.	тулыландыру чыганаклары булган оешмаларның эшләр алып бару буенча инструкцияләрен				
5.3.3.	тулыландыру чыганаклары булган оешмалар эшләренең номенклатураларын				
5.3.4.	тулыландыру чыганаклары булган				

	оешмаларның архивы турында нигезләмәләрне				
5.3.5.	тулыландыру чыганаклары булган оешмаларның эксперт комиссиясе турында нигезләмәләрне				
5.4.	тулыландыру чыганаклары булган оешмалар өчен семинарлар уздыру				
5.5.	архив эше һәм эшләр алып бару мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү				
6.	архивны тулыландыру чыганакларының элегрәк 2012 елда расланган исемлеге булу				

2.6. Эшчәнлекнең 2.5 пунктта күрсәтелгән күрсәткечләре буенча алынган баллар бергә кушыла. Татарстан Республикасы муниципаль архивлары рейтингта баллар кимү тәртибендә эшчәнлек нәтиҗәләренең суммар күрсәткесе буенча урнаша.

2.7. Конкурста катнашучылар тарафыннан җыелган баллар тигез булганда түбәндәгеләре булган муниципаль архивка карата өстенлек бирүче өстәмә критерийлар кулланыла (бер-бер артлы):

сакланучы документларның күләме зур булу;

үтәлгән социаль-хокукый гарызнамәләрнең күп санда булуы;

тулыландыру чыганакларының күп санда булуы;

Дәүләт комитетның эксперт-тикшерү методик комиссиясе каравына җибәрелгән описьларны һәм бүтән документацияне эшләп бетерүгә кире кайтару фактлары булмау.

2.8. Грантның икенче этабында катнашу өчен эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече буенча 1 нчедән алып 20нче урынны яулаган грантка дәгъва кылучылар кертелә.

2.9. Беренче этап нәтиҗәләре буенча Экспертлар советы тарафыннан Конкурсның икенче этабында катнашу өчен хокукы булган грантка дәгъва кылучыларның бертигез (өстенлекләрсез) исемлеге формалаштырыла.

2.10. Экспертлар советы грантка дәгъва кылучыларның икенче этапка керту турында карар кабул итә, карар Дәүләт комитетының рәсми сайтында карар чыгарылган көнне бастырыла.

2.11. Конкурсның икенче этабында катнашуга кертелгән грантка дәгъва кылучылар барлык игълан ителгән номинацияләр буенча (һәр номинациядә бердән артык түгел) әлеге Нигезләмә нигезендә проектларын бер үк вакытта тапшырырга хокуклы.

2.12. Конкурсның икенче этабында катнашу өчен Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы муниципаль архивы проекты тапшырыла, аңа проектның проблемасын кую, максатлары һәм бурычлары, проектны гамәлгә ашыру сроклары (кимендә 3 ел) һәм урыны, төп чараларның тасвирламасы, көтеләчәк нәтиҗәләр, күләмнәре керә.

2.13. Проектка билгеләнгән тәртиптә таныкланган түбәндәге документлар кушып бирелә:

мунициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе имзалаган йөртү хаты;

мунициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының яисә муниципаль архивның дәүләт теркәве турында таныклыгы күчермәсе (монда һәм алга таба – муниципаль архив юридик зат статусына ия булган очракта) (31.12.2016 кадәр бирелгән), йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язма бите (01.01.2017дән соң бирелгән);

мунициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының яисә муниципаль архивның оешма мөһере һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган уставы күчермәсе;

мунициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының яисә муниципаль архивның салым органында исәпкә алынуы турында таныклык күчермәсе;

мунициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының яисә муниципаль архивның җитәкчесе вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе.

2.14. Конкурсның икенче этабында катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 2.12, 2.13 пунктларында каралган документлар әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктындагы 2 абзацы белән билгеләнгән срокларда «Татарстан Республикасы Электрон хөкүмәте» электрон документлар әйләнеше системасы аша җибәрелергә тиеш. Проектта аудио- һәм видеоматериаллар булган очракта, соңгылары Дәүләт комитетына конкурсның икенче этабында катнашу өчен документлар бирелгән көнне китереп тә бирелергә мөмкин, почта аша, Дәүләт комитетының рәсми электрон адресына prm.archive@tatar.ru җибәрелергә дә мөмкин.

2.15. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту өчен нигез – әлеге Нигезләмәнең 2.2, 2.3, 2.12, 2.13 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве, һәм заявкаларны тапшыруның әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктында билгеләнгән срокларын бозып бирү.

2.16. Конкурста катнашуга кертелмәгән грантка дәгъва кылучыларга әлеге Нигезләмәнең 2.15 пункты нигезендә мәгълүмат бирү Экспертлар советы утырышы узган көннән 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

III. Экспертлар советын формалаштыру тәртибе

3.1. Экспертлар советы архив эше белгечләре, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан Экспертлар советы рәисе, рәисе урынбасары һәм әгъзалары – тугыз кеше составында формалаштырыла.

3.2. Экспертлар советы составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

IV. Конкурска тапшырылган проектларны бәяләү тәртибе һәм критерийлары

4.1. Грантка дәгъва кылучы проектларын бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

тапшырылган материалларны бәяләү объективлыгының бәяләү критерийларына катгый туры килүе;

конфиденциальлек.

4.2. Конкурсның икенче этабында грантка дәгъва кылучылар проектларын бәяләү Экспертлар комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләү критерийларына катгый туры килү методы белән эксперт бәяләве рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Баллар һәр критерий буенча аерым-аерым исәпләнә һәм бергә кушып куела.

4.4. Баллар эксперт битләренә кертелә, эксперт имзасы белән таныклана һәм Экспертлар советы рәисенә тапшырыла.

4.5. Эксперт битләре нигезендә конкурсның икенче этабының грантка дәгъва кылучылар рейтингы формалаштырыла, аңа экспертлар комиссиясе рәисе һәм әгъзалары имза сала.

4.6. Проектларны бәяләү критерийлары түбәндәгеләр:

тапшырылган материалларның конкурс максатларына һәм бурычларына туры килүе (1дән алып 10 баллга кадәр);

проект идеясенең оригинальлеге, идеяне чагылдыру тулылыгы, шул исәптән яңа технологияләр, куелган бурычларны гамәлгә ашыруга ярдәм итәрлек аудио- һәм видеоматериаллар кулланып (1дән алып 10 баллга кадәр);

чараларны гамәлгә ашыруга карата программа-максат алымы (1дән алып 10 баллга кадәр);

проектны киләчәктә үстерүнең перспективалы булуы (1дән алып 10 баллга кадәр):

«Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан Республикасы тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулыландыру проектларына ярдәм» номинациясендә: Татарстан Республикасы Архив фондын аудиовизуаль документлар белән тулыландыру; муниципаль архивны туплауның мөмкин чыганаклары санын арттыру; телдән тарихларны яздыруга, муниципаль берәмлекнең аудиовизуаль язмасын булдыруга балаларны, яшьләрне, олы яшьтәгеләрне җәлеп итү;

«Татарстан Республикасы Архив фонды документларының һәм бүтән архив документларының сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм» номинациясендә: электрон төрдәге архив документларыннан файдалану фондын булдыру; файдалану фондыннан документларның электрон күчермәләрен атрибутлаштыру;

документларның электрон күчермәләрен «Татарстан Республикасы Бердәм архив мәгълүмат системасы»на (ТР БАМС ЕАИС) урнаштыру;

«Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм бүтән документларны популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм» номинациясендә: архив документларыннан файдалануга балаларны, яшьләрне, олы яшьтәгеләрне җәлеп итү; архив документларын популярлаштыру максатларында мәгълүмат чаралары оештыру; гражданнарның һәм оешмаларның гарызнамәләрен үтәү срокларын архив документларыннан файдалану фонды исәбенә кыскарту.

проектның методик яктан эшләнеше, Татарстан Республикасының башка муниципаль архивларында гамәлгә ашыру өчен проектны ишәйтү (тиражлау) мөмкинлеге (1дән алып 10 баллга кадәр).

V. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү

5.1. Заявкаларны бирү срогы тәмамланган мизгелдән 10 календарь көн эчендә әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктындагы 2 абзацы һәм 2.13, 2.14 пунктларында күрсәтелгән документлар нигезендә Экспертлар советы утырышлары уздырыла, аларда кергән проектлар кушымта итеп бирелгән документлары белән бергә карала.

5.2. Соңгы 3 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре буенча баллар суммасы (беренче этап) һәм проектны яклау нәтиҗәләре буенча (икенче этап) грантка дәгъва кылучыларның экспертлар комиссиясе рәисе һәм әгъзалары имза салган йомгак рейтингы формалаштырыла.

5.3. Агымдагы елның 12 октябреннән дә соңга калмыйча, рейтинг нигезендә Экспертлар советы конкурста җиңүчеләр исемлеген төзи. Конкурста җиңүчеләр дип әлеге Нигезләмәнең 1.6 пункты нигезендә проектларын гамәлгә ашыру юнәлешләре буенча рейтингта беренче 5 урынны яулаган грантка дәгъва кылучылар таныла.

5.4. Берничә проект бертөрле бәяләү баллары алган очракта, заявкасы башка проектлары бертөрле гомуми бәяләү баллы җыйган заявкалардан алданрак кергән проектка югарырак тәртип номеры бирелә.

5.5. Экспертлар советы карарлары, алар өчен шунда катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән очракта, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, Экспертлар советы рәисе тавышы хәлиткеч була.

5.6. Экспертлар советы утырышы, совет әгъзаларының 2/3се анда катнашкан очракта, тулы хокуклы дип санала.

5.7. Экспертлар советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.8. Конкурста җиңүче грантка дәгъва кылучылар исемлеге Экспертлар советының йомгак беркетмәсе нигезендә агымдагы елның 13 октябренә кадәрге срокта Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

5.9. Грантка дәгъва кылучылар исемлеге боерыкка имза салынган көннән өч эш көне эчендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (www. http://arhiv.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

5.10. Конкурска тәкъдим ителгән проектлар муниципаль архивлар җитәкчеләренең шәхси гаризалары нигезендә конкурс уздырган елдан соң килүче елның 31 декабренә кадәрге срокта кире кайтарыла.

VI. Грантлар алучылар тарафыннан хисапларын тапшыру тәртибе һәм сроклары

6.1. Грант алучылар ел саен, 3 ел дәвамында, Дәүләт комитетына грантлар рәвешендә бирелгән җайланмаларны һәм техниканы максатчан файдалану турында һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 июненә кадәр эшчәнлекләре нәтиҗәләре турында хисаплар тапшыралар.

6.2. Эшчәнлек нәтиҗәләре турындагы хисапта түбәндәге төп позицияләр ачып бирелә:

проектны гамәлгә ашыру тасвирламасы;

«Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан Республикасы тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулыландыру проектларына ярдәм» номинациясендә: проектны гамәлгә ашыру кысаларында саклауга кабул итеп алынган һәм Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертелгән аудиовизуаль документлар саны; муниципаль берәмлекнең телдән башкарылган тарихын булдырганда интервью алынганнар саны;

«Татарстан Республикасы Архив фонды документларының һәм бүтән архив документларының сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм» номинациясендә: Татарстан Республикасы Архив фонды документларыннан һәм бүтән архив документларыннан электрон файдалану фондын булдыру барышында цифрланган документлар саны; Татарстан Республикасы Архив фонды документларыннан электрон файдалану фондын булдыру барышында атрибутланган цифрланган документларн саны; «Татарстан Республикасы Бердәм архив мәгълүмат системасы»на (ТР БАМС ЕАИС) урнаштырылган документларның электрон күчермәләре саны;

«Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм бүтән документларны популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм» номинациясендә: электрон файдалану фондын кулланып башкарылган чаралар саны һәм электрон файдалану фондына мөрәҗәгать иткән тикшеренүчеләр саны; гражданнарның һәм оешмаларның гарызнамәләрен архив документларыннан файдалану фонды исәбенә үтәү сроклары;

барлык номинацияләрдә дә:

җәмәгатьчелек фикеренә күзәтү (массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләре, анкеталаштыру);

фото- һәм видеоматериаллар.

2017 елда Татарстан Республикасы
муниципаль архивларына
грант ярдәме алуга конкурс турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль архивларын үстерү өчен
Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының
грантларын алуга конкурста катнашу өчен
заявка

	Проект атамасы	
	Номинация	
	Муниципаль архивының тулы атамасы (алга таба – учреждение)	
	Муниципаль архив җитәкчесе Ф.Ис.Ат.ис.	
	Муниципаль архивның рәсми адресы	
	Контакт телефоны, e-mail	
	Заявкага кушымталар (билгеләнгән тәртиптә таныкланган): муницициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе имзалаган йөртү хаты; 2014, 2015, 2016 елларга муниципаль архивның расланган еллык хисаплары күчермәләре һәм аларга аңлатма язулары	

Заявканы тутыру датасы _____
Муниципаль архив җитәкчесе имзасы _____Ф.Ис.Ат. ис.
Муницициципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе имзасы _____Ф.Ис.Ат.ис.

М.У.